ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унҗиденче абзац өстәргә:

«янгын чыгу турындагы сигналларны «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законның 83 статьясындагы 7 өлеше нигезендә янгыннан саклану бүлекчәләренә дә кабатлауны оештыру тәртибен раслау;»;

б) унҗиденче абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

2) 15 статьяның беренче өлешендә «оешмаларда» сүзеннән соң «(куркыныч җитештерү объектлары эксплуатацияләнә торган Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган стратегик предприятиеләр һәм стратегик акционер җәмгыятьләр исемлегенә кертелгән дәүләт корпорацияләреннән һәм оешмаларыннан һәм аларга ведомство буйсынуындагы объектлардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 27 июнь
№ 40-ТРЗ